# ЧИШМӘ БАШЫ



Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы «МӨНДЕШ БАЛАЛАР БАКЧАСЫ» МБМББУ, октябрь, 2025 ел № 10

***Ата-аналар һәм балалар өчен мәгълүмати-танып белү газетасы***

***Газетаның сәхифәләре:***

***1. «Юлда булсаң, бул өлгер – юл кагыйдәсен нык бел!»(бәйрәм чарасы)***
***2. «Китапны яратып бүләк ит!» акциясе***
***3. «Фән сәгате» исемле тематик эшчәнлекләр***
***4. Балалар бакчасында ГТО!***

**Баш мөхәррир:**
**балалар бакчасы мөдире**
**Мостафина Рима Галип кызы.**
**Мөхәррир урынбасарлары:**
**музыка җитәкчесе Хөсәенова Г.Ф.**
**тәрбиячеләр: Хөсәенова Р.Р.,**
**Җәләлиева А.Г., Шәкүрова Р.С.,**
***Хөсәенова В.В.***

«

## *«Юлда булсаң, бул өлгер – юл кагыйдәсен нык бел!»*

Юл йөрү кагыйдәләрен машина йөртүчеләр генә түгел, жәяүлеләр дә яхшы белергә тиеш, чөнки еш кына алар гаебе белән юлларда төрле фаҗигаләр була. Аларда күбесенчә балалар зыян күрә, имгәнә, гарип кала. Бу бик кызганыч, авыр хәл. Мондый фаҗигаләр килеп чыкмасын өчен без бакчабызда һәрвакыт юл йөрү кагыйдәләрен искә төшереп торабыз. Төрле табышмаклар чишәбез, презентацияләр карыйбыз, пазллар төзибез, китаплар укыйбыз.

15 нче октябрьдә бакчабызда зурлар төркеме балалары белән юл йөрү кагыйдәләренә багышланган чара булып узды. Бу чарага Арча шәһәренең ЮХИДИ хезмәткәре Мухаметзянова Энҗе Газиз кызы килде. Балалар юл кагыйдәләре турында булган белемнәрен урманнан шәһәргә килгән “Шүрәлегә” өйрәттеләр, юлда сак йөрергә, юл кагыйдәләрен төгәл үтәргә кирәклегенә төшендерделәр.








## ***«Китапны яратып бүләк ит!»***

Китаплар бүләк итү бик матур һәм кирәкле күренеш. Әти-әниләргә, балаларның төрле омтылышлары һәм ихтыяҗлары өчен тиешле шартлар тудыру, төркемнең китап фондын формалаштыру, баету максатыннан, «Балалар бакчасына Китап бүләк ит» акциясе тәкъдим ителде.









*Балалар яратып карый, укый торган, матур, кызыклы китаплар алып килгән һәрбер әти-әнигә зур рәхмәтебезне белдерәбез!*

Бакчабызда даими рәвештә октябрь аеннан башлап “Фән сәгате” исемле тематик эшчәнлекләр һәм төрле чаралар үткәрелә башлады.

***“Һаваны ничек табып була”*** дигән темага эшчәнлек барышында балалар белән һаваның үтәкүренмәле булуы, күзгә күренмәве, иссез булуы, һава агымыннан җил барлыкка килүе һәм тереклек өчен һаваның бик мөһим булуы турында сөйләштек.



***“Алтын хохлома”*** эшчәнлегендә балаларны хохлама бизәкләренең килеп чыгу тарихы белән таныштырдык. Хәзерге заман хохлама бизәге белән савыт-саба бизәүче осталарның эшләре төрле музейларда, күргәзмә залларына куелуы турында сөйләнде.






***“Авазлар һәм музыка”*** дигән фән сәгатендә исә балалар белән музыкаль инструментларга багышланган презентация карадык, “Авазлар эзлибез” дигән музыкаль-дидактик уен аша музыка һәм авазлар турында белемнәрне ныгыттык.



## *Балалар бакчасында ГТО!*

Арчаның 8 нче балалар бакчасында “ГТО уеннары” фестивале узды. Командада 1 малай һәм 1 кыз - 6-8 яшьлекләр катнашты. Балалар озынлыкка сикерделәр, идәнгә йөзтүбән ятып, кулларга таянып, идәнгә аркалары белән ятып күтәрелделәр.

*Арча районында ГТО буенча белгеч Зөһрә Җамалиева: “Балалар бакчаларында ГТО күптәннән бара инде. Ә менә фестиваль беренче тапкыр. Балалар молодцы, җитезләр, көчлеләр. Кечкенәдән өйрәнеп, чыныгып үсәргә кирәк шул”.*

*8 нче балалар бакчасы физик тәрбия инструкторы Гөлназ Диярова болай дип өстәде: “Һәрбер бакчада атнасына 3 тапкыр физик тәрбия дәресләре уздырыла. Төрле физик күнегүләр эшләнә, хәрәкәтле уеннар уйнала”.*

Безнен балалар бакчасы да бүгенге көндә сәламәт яшәү рәвешен үстерү максатыннан бик күп төрле спорт чаралары уздыра.



